| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>БУРУНДУКОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>БОРЫНДЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10 ноябрь, 2023 ел Борындык авылы №2

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Шүширмә авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. 2023 елның 27 ноябрендә 11 сәг 00 минутка Шүширмә авылы, Ямашев урамы, 1 нче йорт адресы буенча урнашкан клуб зданиесендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Шүширмә торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***беренче этабын*** билгеләргә.
2. 2023 елның 27 ноябрендә 15 сәг 00 минутка Шүширмә авылы, Гагарин урамы янында урнашкан ООО “Туган як- Агро” административ зданиесендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Шүширмә торак пунктында үзара салым алып бару мәсьләләре буенча гражданнар җыенының ***икенче этабын*** билгеләргә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны урыны буенча Шүширмә авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

авыл җирлеге территориясен төзекләндерү:

- авыл җирлегенең торак пункты территориясен карап тоту;
- урамнардагы яктырткычларны ремонтлау, моның өчен материаллар сатып алу;

- авыл жирлегендә торак пунктлардагы чүплекләр территорияләрен чистарту;

авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:

-суүткәргеч челтәрен ремонтлау һәм моның өчен материаллар, җиһазлар сатып алу;

- су башнясын ремонтлау һәм моның өчен материаллар, җиһазлар сатып алып аңа хезмәт күрсәтү;

авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:

- юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу;
- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору;

авыл җирлеге чикләрендәге халыкны беренчел янгын куркынычсызлыгы чарасы белән тәэмин итүне оештыру:

- янгын сүндерү машинасын, янгын сүндерү депосы җиһазларын һәм бүлмәләрен карап тору.

Экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлеге башкарма комитетына җыен белән билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

« РИЗА» «КАРШЫ».

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Борындык авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Борындык авыл җирлеге
Башлыгы А. Р. Гайнетдинов